СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗƏЛƏ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2018 ел г.Мензелинск №3

**Совет карары проекты турындагы «Минзәлә муниципаль районының 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 15, 28 ст. нигезендә,
шулай ук Минзәлә муниципаль районы Уставының 90, 91 ст.

Минзәлә муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының «2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына Минзәлә муниципаль районы бюджеты турында " гы Карары проектын хупларга һәм халык тыңлауларына чыгарырга»
2. 2018 елның 7 декабрендә 14.00 сәгатьтә «Минзәлә муниципаль районының 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты турында»проекты буенча администрациянең утырышлар залында,халык тыңлаулары уздырырга.
3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советына халык тыңлаулары үткәрүне, әлеге карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.
4. «Минзәлә муниципаль районының 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына бюджеты турында» проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча биш кешедән торган комиссия төзү:

- Гатина А. Г.-комиссия җитәкчесе
- Газизҗанов Р. Ш.-комиссия әгъзасы
- Кузнецов Э. И.-комиссия әгъзасы
- Фәттахов Р. Ш.-комиссия әгъзасы
- Леванов А. Д.-комиссия әгъзасы
- Секунов Н. С.- комиссия әгъзасы

5. Әлеге карарны «Минзәлә» - «Мензеля» газетасында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Минзәлә
муниципаль район башлыгы
Совет Рәисе А. Ф. Сәлахов